ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.09.2019 Казан ш. № 7-9/т

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифлар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы һәм «Тимер юлда ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне дәүләти җайга салу турында» 2009 елның 5 августындагы 643 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Тимер юлда ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары эшләренә (хезмәтләренә) карата тарифларны, җыемнарны һәм түләүне билгеләү (үзгәртү) мәсьәләләрен карау тәртибен, шулай ук аларны билгеләү (үзгәртү) өчен тапшырыла торган документлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 19 августындагы 506-Т номерлы боерыгы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Шәһәр яны билгеләнешендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспортында пассажирлар ташу өлкәсендә табигый монополияләр субъектлары хезмәтләре өчен икътисадый нигезләнгән тарифлар дәрәҗәсен формалаштырганда исәпкә алына торган икътисадый нигезләнгән чыгымнар дәрәҗәсен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2017 елның 5 декабрендәге 1649/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашырыла торган шәһәр яны тимер юл транспортында Казан-Кизнер, Кизнер-Казан, Ижевск-Кизнер, Кизнер-Ижевск маршрутлары буенча уңайлылык дәрәҗәсе югары булган вагоннарда пассажирлар йөртүгә әлеге карар кушымтасының 1 нче пунктында билгеләнгән тарифларга өстәмә тарифлар билгеләргә, түбәндәге күләмнәрдә:

- 1 класска караган вагонда – 60 сум;
- 2 класска караган вагонда – 40 сум.

3. Уңайлылык дәрәҗәсе югары булган вагонда бару бәясен түләү пассажир тарафыннан ул бара торган барча юл озынлыгына бер мәртәбә, әлеге карар кушымтасының 2 нче пунктында билгеләнгән тарифларга туры китереп түләнә.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 16 декабрендәге 7-5/т номерлы;

«Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга икътисадый нигезләнгән тариф дәрәҗәсен билгеләү турында» 2016 елның 25 ноябрендәге 7-17/т номерлы.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.09.2019 № 7-9/т карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны билгеләнешендә тимер юл транспорты белән «Содружество» акционерлык җәмгыяте тарафыннан пассажирлар ташуга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| № п/п | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә иң зур тариф, сумнарда | 5 яшьтән 7 яшькәчә кадәрге балаларны алып баруга иң зур дәрәҗәдә чик тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Юл озынлыгына бәйсез рәвештә, сәфәр кылу маршрутының беренче дистә километрыннан башлап икенче дистә километрына кадәр бер пассажирны алып бару | 1 сәфәр | 24,00 | 6,00 |
| 2. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны өченче дистә километрдан башлап дүртенче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 18,00 | 4,50 |
| 3. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны бишенче дистә километрдан башлап сигезенче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 16,00 | 4,00 |
| 4. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны унынчы дистә километрдан башлап унөченче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 14,00 | 3,50 |
| 5. | Пассажир юнәлгән юл буйлап, һәр зона өчен өстәмә рәвештә бер пассажирны ундүртенче дистә километрдан башлап егерменче дистә километрлы зонага алып бару | 1 зона | 12,00 | 3,00 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге